ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 011 от « 09 » 02 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә премия бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Мамадыш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 3-25 номерлы карары нигезендә к а р а р б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә премия бирү турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлеше буенча җаваплы итеп Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе В.Н.Фәизовны билгеләргә.

Муниципаль
район Башлыгы А.П. Иванов

000014

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы башлыгының
09 02 2022 ел, №
011 карарына кушымтa

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә премия бирү турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми Нигезләмәләр

1.1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, муниципаль хезмәткәрләрнең эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру, җирле үзидарә органнарына йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү, башкарыла торган бурычларның сыйфатын яхшырту, вазыйфаи инструкциядә каралган вазыйфаи бурычларны вакытында һәм намуслы үтәгән өчен, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә түбәндәге төр премияләр түләнә:
- аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия;
- квартал саен бирелә торган премия;
- һөнәри бәйрәмнәргә, бәйрәм һәм юбилей даталарына премия;
- елына эш нәтиҗәләре буенча еллык премия.
1.2. Премияләрне түләүгә чыгымнарны финанслау җирле бюджет акчалары, хезмәткә түләү фондын экономияләү, финанс елына бюджет турында расланган бюджеттан тыш фактта алынган керемнәр һәм агымдагы финанс елы башына барлыкка килгән район бюджеты счетында калган акчалар, оптимизация чаралары үткәргәндә, җирле бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.
1.3. Премия түләү һәм аннан мәхрүм итү рәсмиләштерелә:
1.3.1. Җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә – Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының җирле үзидарә органы җитәкчесе, структур бүлекчәсе җитәкчесе күрсәтмәсе (боерыгы) белән.
1.4. Премия күләме билгеләнә:
- - аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне башкарган өчен премия вазыйфаи окладтан процентлы рәвештә;
- календарь, милли бәйрәм чараларына багышланган һәм аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен бер тапкыр бирелә торган премия өчен квартал саен бирелә торган премияләр күләмендә;
- җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең юбилей даталарына бер генә вазыйфаи оклад күләмендә;
- хезмәт хакы фонды буенча барлыкка килгән экономия кысаларында.
1.5. Муниципаль район Башлыгы, муниципаль район Башлыгы урынбасары,

муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчеләре, республика һәм федераль хакимият органнары күрсәтмәләре нигезендә дә премияләр ала алалар.

1.6. Әлеге Нигезләмәнең 3-5 бүлекләрендә каралган премияләрнең гомуми күләме календарь ел эчендә муниципаль вазыйфаларны, муниципаль хезмәткәрне биләүче затның унике акчалата кеременнән артып китә алмый.

1.7. Әлеге Нигезләмәнең 3 һәм 5 бүлекләрендә билгеләнгән премияләр аерым муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль вазыйфаны биләүче затларга индивидуаль рәвештә түләнергә мөмкин.

1.8. Премия бирү мәсьәләләре буенча шәхси хезмәт бәхәсләре хезмәт законнарында билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

**2. Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия**

2.1. Эш нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрләргә аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен, фактта эшләнгән вакыт өчен хезмәт хакының бер проценты күләмендә премия түләнә.

2.2. Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия түбәндәге очракларда түләнми:

- 3 һәм аннан да күбрәк документларны карау вакыты бозылганда (мөрәҗәгатьләр, хатлар);
- ай дәвамында район Башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесенең 1 һәм аннан да күбрәк беркетмә йөкләмәләрен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен;
- милекне юк итүгә китермәгән муниципаль милеккә матди зыян китергән өчен;
- шелтә рәвешендә аена 2 тапкырдан артык дисциплинар җәза булу;
- вазыйфаи бурычларны үтәгәндә билгеле булган хезмәт мәгълүматын тарату;
- муниципаль хезмәт үтүгә бәйле чикләүләрне һәм тыюларны, хезмәт тәртибе йөкләмәләрен һәм кагыйдәләрен, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен үтәмәү, коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәү.

**3. Квартал саен бирелә торган премия**

3.1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә эш бирүче карары буенча квартал саен бирелә торган премияләрне түләү гамәлгә ашырылырга мөмкин.

3.2. Тулы булмаган ай эшләгән муниципаль хезмәткәргә, муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка эш нәтиҗәләре буенча премия фактта эшләнгән вакыт өчен түләнә.

3.3. Квартал саен бирелә торган премияләр киметелергә мөмкин:

- гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау срокларын үтәмәгән очракта, шул исәптән бүтән учреждениеләр, оешмалардан кергән мөрәҗәгатьләр буенча, хезмәт документлары белән эшләү тәртибен бозганда - 50 % кадәр;
- кисәтү рәвешендә дисциплинар җәза алган өчен-50% кадәр, шелтә алган өчен-100% кадәр ;

- район Башлыгы, җирле үзидарә органы Җитәкчесе беркетмәсен үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен - 50 % кадәр;
- хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәмәгән өчен - 20% кадәр.
- программаны яки аның аерым чараларын вакытында һәм сыйфатсыз гамәлгә ашырган өчен озак сроклы муниципаль программаларны башкаручыларга, программаны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән район бюджеты акчаларыннан нәтиҗәле һәм максатчан файдалануны тәэмин итмәгән җаваплы кешеләргә - 50% кадәр.
3.4. квартал саен бирелә торган премиянең күләме бер айлык акчалата түләүдән арта алмый.
3.5. Квартал саен бирелә торган премияләр эш бирүче карары буенча, шулай ук вазыйфаи бурычларны үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү сәбәпле, аена 2 тапкырдан артык тапкыр чыгарылган шелтә рәвешендә дисциплинар җәза булганда түләнә алмый.
3.6. Хезмәткәрләрнең саны яисә штаты кимүгә бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә, медицина бәяләмәсе нигезендә сәламәтлеге торышы буенча, башка эшкә күчүгә, уку йортына керүгә, пенсиягә чыгуга, хәрби хезмәткә чакырылуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затларга квартал саен бирелә торган премияне түләү расланган вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла.
3.7. Квартал саен бирелә торган премия түләү муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә түбәндәге вакытта түләми:
- баланы карау ялында булганда;
- өч айдан артык дәвамлылыкта акчалата түләү сакламыйча отпускта булганда.

**4. Һөнәри бәйрәмнәргә, бәйрәм һәм юбилей даталарына туры китерелгән премия**

4.1. Һөнәри бәйрәмнәргә, бәйрәм һәм юбилей даталарына туры китерелгән премия бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк булып тора.
4.2. Һөнәри бәйрәмнәргә туры китерелгән премия бәйрәм һәм юбилей даталарына туры китереп муниципаль вазыйфаларны биләүче барлык затларга,җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләргә һөнәри бәйрәм, бәйрәм һәм юбилей даталарына түләнә.
4.3. Һөнәри бәйрәмнәргә, бәйрәм һәм юбилей даталарына туры китерелгән премия айлык акчалата түләүдән артык бирелә алмый.

**5. Ел нәтиҗәләре буенча еллык премия**

5.1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга һәм муниципаль хезмәткәрләргә бер ел эшләү нәтиҗәләре буенча еллык премия түләнә ала.
5.2. Ел нәтиҗәләре буенча премия күләме хезмәткә түләү фондының экономияләү күләменә карап билгеләнә.
5.3. Тулы булмаган ел эшләгән муниципаль хезмәткәргә, муниципаль вазыйфаны биләүче затка премия фактта эшләнгән вакыт өчен түләнә.

5.4. Еллык премияләр, елына 3 тапкырдан артык чыгарылган шелтә рәвешендә дисциплинар җәза булганда, вазыйфаи бурычларны үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү сәбәпле, тулысынча түләнми.
5.5. Еллык премия муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә түбәндәге вакытта түләнми:

- баланы карау ялында булганда;
- өч айдан артык дәвамлылыкта акчалата түләү сакланмыйча отпускта булганда.

Аппарат җитәкчесе В.Н.Фәизов